СОВЕТ УРАЗБАХТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.1а, с. Уразбахтино,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422155

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРАЗБАХТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., 1 нче а йорт, Уразбахты авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422155

тел.(факс): (85563) 2-86-36; e-mail: UrBah.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

№ 1-38 01.10.2018

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларының куллану максатын үзгәртү буенча җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Уразбахты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Уразбахты авыл җирлеге башкарма комитетының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2018 нче елның 27 нче сентябрендә кабул ителгән 19 номерлы карары, Уразбахты авыл җирлеге Советының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2018 нче елның 27 нче сентябрендә кабул ителгән 1-37 номерлы карары, Уразбахты авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Уразбахты авыл җирлегендә гражданнардан узара салым акчасын җыю һәм куллану кагыйдәләре” 2014 нче елның 2 нче апрелендә кабул ителгән 2-31 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын куллану максатын үзгәртү буенча җирле референдум үткәрү көнен 2018 нче елның 18 нче ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру: Уразбахты торак пунктында урамнарны яктырту объектларын модернизацияләүгә (агымдагы ремонт, җирлек территориясендә урам утлары лампалары сатып алу һәм алмаштыру) өчен” каралган, 2016 елда гражданнардан җыелган үзара салым акчасының 154,5 мең сум күләмендә калган өлешен “Җирлекнең торак пунктлары

чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру: Уразбахты торак пунктының Комсомол урамы юлларын вакташ җәеп ремонтлау” өчен үзгәртелүенә сез ризамы:

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге башлыгы Р.Г.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе /Р.Г.Шәйхетдинов/